РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

3 март, 2026 ел №16

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2022 елның 10 октябрендәге 49 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясындагы 3 пунктының «г», «д» пунктчалары нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны федераль законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2022 елның 10 октябрендәге 49 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

Күрсәтелгән карар белән расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5.1 пунктында 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк булган очракта, һәм әгәр федераль закон нигезендә мондый шәхси күрсәткечләрне эшкәртү күрсәтелгән зат ризалыгы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булса, муниципаль хезмәтне алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче өстәмә рәвештә «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең әлеге затның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә

ризалыгын алуын раслый торган документларны тапшыра. Рөхсәт алуны раслый торган документлар, шул исәптән, электрон документ формасында да тапшырылырга мөмкин;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Андреев В.Н.